МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И
ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.09.2024 Казан шәһәре № 174-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карарлары нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Коррупциягә каршы экспертизаны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының юридик бүлеге җитәкчесенә Тәртип белән эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы идарәләре һәм бүлекләре җитәкчеләренә коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының юридик бүлегенә норматив хокукый актлар проектларын вакытында тапшырырга.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 7 сентябрендәге 208-ОД номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2024 елның _______________ _____ номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына аларда коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны бетерү максатларында коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын билгели (алга таба, тиешенчә – Тәртип, Министрлык).

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карарлары, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып актларда һәм актларның проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү тору.

1.4. Актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларның хокукый экспертизасы үткәрелгәндә үткәрелә.

Актларга коррупциягә каршы экспертиза аларның кулланылышын мониторинглаганда, шулай ук Министрлыкка Министрлык актларында коррупциячел факторлар булуы турында мәгълүмат ирешкән очракта үткәрелә.

1.5. Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата үткәрелми.

## II. Министрлык актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру

2.1. Министрлык актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкта коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат (алга таба – вазыйфаи зат) тарафыннан үткәрелә.

Вазыйфаи зат Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры (алга таба – министр) тарафыннан Министрлыкның юридик бүлеге хезмәткәрләре арасыннан билгеләнә.

Әлеге вазыйфаи зат шулай ук Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта) алып бару өчен дә җаваплы булып тора.

2.2. Актлар һәм актларның проектлары коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен әлеге актны кабул итү инициаторы булган структур бүлекчә җитәкчесе (акт проектын әзерләү өчен җаваплы зат) тарафыннан вазыйфаи затка җибәрелә.

Актлар шулай ук коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Министрлык җитәкчелеге тарафыннан да җибәрелергә мөмкин.

2.3. Акт (акт проекты) коррупциягә каршы экспертизага кергәндә, вазыйфаи зат бер эш көне дәвамында кирәкле мәгълүматны Журналга кертә һәм актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза үткәрә.

Коррупциягә каршы экспертиза актны Журналда теркәгән көннән соң ункөнлек чорда уздырыла.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага тапшырылган актның реквизитлары (акт проектының аталышы);

коррупциягә каршы экспертиза уздыру нигезе;

актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булуы яки юклыгы;

актның (акт проектының) коррупциячел факторларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре (булган очракта);

акт проектын акт нигезләмәләрен үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен (коррупциячел факторлар ачыкланганда) аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру юлы белән үзгәртү буенча тәкъдимнәр.

2.5. Вазыйфаи зат әзерләгән һәм кул куйган актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән бәяләмә әлеге актны (акт проектын) коррупциягә каршы экспертизага җибәргән затка һәм министрга аңа кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

2.6. Эшләп чыгаручы зат коррупциягә каршы экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелгән бәяләмәне алган көннән алып өч эш көне эчендә акт проектын эшләп бетерә һәм эшләнеп беткән проектны вазыйфаи затка кабат карауга җибәрә.

Әгәр актта коррупциячел факторлар ачыкланса, актны кабул итү инициаторы булган зат бәяләмәне алгач, өч эш көне эчендә үзгәрешләр кертү яисә коррупциягә каршы экспертиза предметы булган актның көчен югалтуын тану турында норматив хокукый акт проектын әзерләргә һәм коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен вазыйфаи затка җибәрергә тиеш.

Кабат коррупциягә каршы экспертиза эшләнеп беткән акт проекты кергән көннән алып өч эш көне эчендә уздырыла.

2.7. Әгәр экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупциячел факторлар булмаса, акт проектын әзерләп бирүче зат мәнфәгатьле структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән бергә акт проектын имза салу өчен министрга җибәрә яисә акт проектының мәнфәгатьле органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен җибәрелүен тәэмин итә.

## III. Министрлык актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

3.1. Министрлыкның рәсми басылып чыккан һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – сайт) яки, үзләренә карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар буенча иҗтимагый фикер алышу максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар буенча иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет-порталы (алга таба – бердәм төбәк интернет-порталы) буларак билгеләнгән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган норматив хокукый актлары, Министрлык тарафыннан эшләнгән актларның проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрдән торган мәгълүматларны үз эченә алган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелми.

Министрлык тарафыннан эшләнә торган, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен, вазыйфаи зат аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм бердәм төбәк интернет-порталында республиканың мәнфәгатьле республика башкарма хакимият органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен юлланган эш көне дәвамында урнаштыра.

3.2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, вазыйфаи зат Министрлыкның акт проектын аны карау өчен хокукый бүлеккә җибәргән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында Министрлык акты проектын бердәм төбәк интернет-порталында һәм Министрлык сайтында эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау датасын күрсәтеп урнаштыра.

актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы мондый урнашу көненнән кимендә биш эш көне тәшкил итә.

3.3. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча срок чикләрендә Министрлыкка алынган бәяләмә (алга таба – бәяләмә) килгән көненнән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы булган Министрлыкның структур бүлекчәсенә, шулай ук бридик бүлеккә карау өчен җибәрелә.

3.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкында була. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә, әлеге Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, аны теркәгән көннән 15 көн эчендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка  нигезләнгән җавап (бәяләмәдә ачыкланган коррупция факторлары турында мәгълүмат яки ачыкланган коррупция факторларын бетерү ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш) җибәрелә, анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләренең исәпкә алынуы һәм (яки) актта яки акт

проектында ачыкланган коррупция факторы белән риза булмау сәбәпләре чагылдырыла.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килми торган.

Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Министрлык мондый бәяләмәне, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлү көненнән соң 15 көннән дә соңга калмыйча кире кайтара.

3.6. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар акт проектын өстәмә эшләү стадиясендә аны әзерләүче зат тарафыннан бетерелә.

Эшләүче тарафыннан акт проектына аңа коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырылганнан соң үзгәрешләр кертелгән очракта, акт проекты яңадан коррупциягә каршы бәйсез экспертизага тиешле була.

Коррупциягә каршы кабат бәйсез  экспертиза проект бердәм төбәк интернет-порталында урнаштырылган көннән алып өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.7. Актта коррупциячел факторлар ачыкланса, актны әзерләүче бәяләмәне теркәгән көннән алып өч эш көне эчендә актка үзгәрешләр кертү яки аны үз көчен югалткан дип тану чараларын күрә.

3.8. Актны әзерләүче зат әзерләнгән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнарның проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, әзерләүче зат күрсәтелгән норматив хокукый актларның проектларын, коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризалашмавын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карау өчен кертә.

## IV. Министрлыкның норматив хокукый актлары проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу

4.1. Министрлык эшләнә торган норматив хокукый актларын проектлары турында иҗтимагый фикер алышуларны тәэмин итә.

4.2. Иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актлар проектлары бердәм төбәк интернет-порталында урнаштырыла.

4.3. Гражданнарның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган норматив хокукый актларның проектлары иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен бердәм төбәк интернет-порталында урнаштырыла.

4.4. Иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләре яки конфиденциаль холыклы белешмәләре булган норматив хокукый актларның проектлары;

норматив хокукый актларны (аларның структур берәмлекләрен) көчен югалткан дип тану турында норматив хокукый актларның проектлары;

аларны әзерләү өчен Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән срок иҗтимагый фикер алышуның минималь срогыннан азрак (бердәм төбәк интернет порталында урнаштыру көненнән соң биш эш көнненән азрак) булган норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яки чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актларның проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актларның проектлары;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларның проектлары;

террорчылыкка, шул исәптән террорчылыкны финанслауга, каршы көрәш чараларын тормышка ашырганда дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен регламентлый торган норматив хокукый актларның проектлары;

бәяләр (тарифлар) билгеләү турында норматив хокукый актларның проектлары;

мөлкәт белән идарә иткәндә билгеләнә торган бәяләрне (түләү күләмен) билгеләү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актларның проектлары;

суд карарларын, прокурор йогынтысы актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен тормышка ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актларның проектлары;

дәүләт функцияләре үтәүнең административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында норматив хокукый актларның проектлары.

4.5. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен норматив хокукый актларның проектлары урнаштырылганда проект әзерләү инициаторы булган структур бүлекчә тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук иҗтимагый фикер алышу срогының башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

4.6. Норматив хокукый актларның проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу срогы бердәм төбәк интернет порталында урнаштырган көненнән башлап биш эш көненнән азрак була алмый.

4.7. Документны эшләүче зат тарафыннан иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проектын өстәмә эшләү турында карар кабул ителгән очракта, өстәмә эшләнгән норматив хокукый акт проекты шулай ук иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырыла.

4.8. Норматив хокукый актларның проектларын бердәм төбәк интернет порталында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы, иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 30 көнлек срокта актны (акт проектын) эшләче өчен җаваплы зат коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру барышында ачыкланган коррупциячел факторлар, иҗтимагый фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүматларны аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган форма буенча урнаштыра.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 1 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналы

| Актның (акт проектының) экспертизага килү датасы | Актны (акт проектын) тапшырган структур бүлекчә | Актның (акт проектының) аталышы | Бәяләмә (коррупциячел нормалар булу/ булмау), бәяләмәне төзү датасы | Экспертизаны уздыру өчен җаваплы зат | Искәрмә (шул исәптән кабат экспертиза уздыру турында мәгълүмат, кабат экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү датасы) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм
сәүдә министрлыгының норматив
хокукый актларына һәм норматив
хокукый актлары проектларына
коррупциягә каршы экспертиза уздыру
тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза
БӘЯЛӘМӘСЕ

____________________________________________
(экспертиза уздыру датасы)

Экспертизага тапшырылган актның (акт проектының) атамасы һәм реквизитлары ____________________________________________________________
_________________________________________________________________________.

Коррупциягә каршы экспертиза уздыру нигезе - ___________________________
_________________________________________________________________________.

Актта (акт проектында) коррупциячел факторларның булуы яки булмавы: ___
_________________________________________________________________________.

Актның (акт проектының) коррупциячел нормаларны үз эченә алган конкрет нигезләмәләре: _________________________________

Акт (акт проекты) нигезләмәләрен үзгәртү яки коррупциячеллекне бетерү өчен аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру юлы белән үзгәртү буенча тәкъдимнәр: ____
_________________________________________________________________________.

_____________________________________________ _______________________________
(җаваплы затның вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.А. (ата исеме - булган очракта)